Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
«Лашман авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
гражданнары җыены

**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Лашман авыл җирлеге составына керүче Әмир торак пунктында

07 ноябрь 2019 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге составына керүче Әмир торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2020 елда Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәүче һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә гражданнарның үзара салымын кертергә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 90 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш.

2. Алынган чараларны җибәрергә:

- Әмир торак пунктында бишенче чыбыкны монтажлауга, энергия саклаучы яктырткычлар урнаштыруга, ремонтка, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләүгә, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга;
- Әмир торак пунктында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту) чыгымнарына, трактор өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алуга, хезмәт хакы тракторчыга исәпләү белән югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Әмир торак пунктында урам-юл челтәрен ремонтлауга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Лашман авыл җирлеге башлыгы Р.Г.Фәттахов